СОВЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

23.10.2020 г.Зеленодольск № 17

Зеленодольск муниципаль районы Советының 2015елның 27 мартындагы 517 номерлы «Зеленодольск муниципаль районы Советы каршындагы муниципаль Яшьләр парламентын төзү турында» гы карарына үзгәрешләр кертү турында ( Зеленодольск муниципаль районы Советының 2015 елның 10 июлендәге 544 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләр белән)

Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Зеленодольск муниципаль районы Советы «Зеленодольск муниципаль районы Советы каршында муниципаль Яшьләр парламенты төзү турында» 2015 елның 27 мартындагы 517 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында мәгълүматын тыңлап фикер алышканнан соң, Зеленодольск муниципаль районы Советы **карар итте**:

1. Зеленодольск муниципаль районы Советының 2015 елның 27 мартында кабул ителгән 517 номерлы «Зеленодольск муниципаль районы Советы каршындагы муниципаль Яшьләр парламентын төзү турында» гы карарына (Зеленодольск муниципаль районы Советының 2015 елның 10 июлендә кабул ителгән 544 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Карарның исемен яңа редакциядә бәян итәргә:

«Зеленодольск муниципаль районы Советы каршындагы Яшьләр парламентын төзү турында»;

1.2. Карарның 1 пунктында «муниципаль» сүзен төшереп калдырырга;

1.3. Карарның 2 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә:

«Зеленодольск муниципаль районы Советы каршындагы Яшьләр парламенты нигезләмәсен расларга (1 нче кушымта)»;

1.4. Зеленодольск муниципаль районы Советы каршындагы Яшьләр парламентының нигезләмәсен яңа редакциядә әлеге карарга кушымта нигезендә расларга.

2. Әлеге карарны «Интернет»мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре

порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының рәсми сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны законлылык, хокук тәртибе, регламент һәм депутат этикасы мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

**Зеленодольск муниципаль районы Башлыгы Совет Рәисе** **М.П. Афанасьев**

Расланган
Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Советы
№17 2020 елның 23 октябре

# Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Совет каршындагы Яшьләр парламенты турында Нигезләмә

## I. Гомуми нигезләмәләр

1. Зеленодольск муниципаль районы Советы каршындагы Яшьләр парламенты (алга таба – Яшьләр парламенты) яшьләр хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен законнар белән һәм норматив – хокукый җайга салу, яшьләр проблемаларын хәл итү буенча тәкъдимнәр әзерләү, яшьләр өчен шартлар тудыру, Россия яшьләр парламентаризмы хәрәкәтендә Зеленодольск муниципаль районы яшьләренең катнашуы максатында оештырыла.

2. Яшьләр парламенты Зеленодольск муниципаль районы Советы каршындагы киңәшмә һәм консультатив орган булып тора һәм үз эшчәнлеген әлеге Нигезләмә һәм Яшьләр парламенты регламенты нигезендә җәмәгать башлангычларында гамәлгә ашыра.

3. Яшьләр парламенты Зеленодольск муниципаль районы Советы вәкаләтләре вакытында формалаша.

## II. Яшьләр парламентының төп бурычлары

4. Яшьләр парламентының төп бурычлары булып түбәндәгедәр тора:

1) яшьләрнең хокукларына һәм законлы мәнфәгатьләренә кагылышлы Зеленодольск муниципаль районы территориясендә кулланыла торган норматив - хокукый актларны (алга таба – норматив - хокукый акт) эшләгәндә яшь гражданнарның инициативаларын тәкъдим итүдә булышлык күрсәтү;

2) яшьләрнең хокуклары һәм законлы мәнфәгатьләре өлкәсендә норматив-хокукый актларны камилләштерү буенча тәкъдимнәр эшләү;

3) яшьләрнең хокукларына һәм законлы мәнфәгатьләренә кагылышлы муниципаль хокукый актларны карауга әзерләү буенча Совет эшчәнлегендә катнашу;

4) яшьләрнең хокукларына һәм законлы мәнфәгатьләренә кагылышлы муниципаль хокукый актлар мониторингын гамәлгә ашыру Советы эшчәнлегендә катнашу;

5) Зеленодольск муниципаль районы территориясендә яшьләрнең хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклау өлкәсендә законнарны гамәлгә ашыруга җәмәгать контролен гамәлгә ашыру;

6) яшьләр арасында яшьләрнең хокукый культурасын һәм юридик белемен күтәрүгә һәм актив гражданлык позициясен формалаштыруга юнәлдерелгән агарту

һәм аңлату эшләре алып бару;

7) дәүләт яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыру буенча җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында яшь гражданнарның фикерен өйрәнү;

8) иҗтимагый әһәмиятле идеяләрне һәм инициативаларны алга этәрү һәм аларга ярдәм итү, тәҗрибә уртаклашу максатларында халыкара, гомумроссия, төбәкара, төбәк һәм җирле яшьләр һәм балалар иҗтимагый берләшмәләре белән даими хезмәттәшлекне гамәлгә ашыру;

9) Татарстан Республикасы Дәүләт Советы каршындагы Яшьләр парламенты белән хезмәттәшлекне гамәлгә ашыру;

11) Яшьләр парламентын булдыру максатларына туры килә торган һәм законнарга каршы килми торган башка мәсьәләләрне хәл итү.

## III. Яшьләр парламентын формалаштыру тәртибе һәм составы

5.Яшьләр парламенты әгъзалары булып Зеленодольск муниципаль районы территориясендә яшәүче, Яшьләр парламенты әгъзасы буларак вәкаләтләрен раслау көненә 18 яшьтән 35 яшькә кадәрге Россия Федерациясе гражданнары була ала.

6. Яшьләр парламенты, конкурс нигезендә Зеленодольск муниципаль районы яшьләрен тәкъдим итүче гражданнардан, кимендә 25 кеше исәбеннән, әмма район Советы депутатлары саныннан артыграк булмаган күләмдә төзелә. Яшьләр парламенты әгъзаларының һәм персональ составның йомгаклау санын билгеләү, әлеге Нигезләмә нигезендә, Совет Президиумы тарафыннан билгеләнә.

7. Әлеге Нигезләмәнең 6 пунктында күрсәтелгән яшьләр вәкилләреннән торган Яшьләр парламентының персональ составы әлеге Нигезләмәгә кушымта булган, яшьләр парламентын формалаштыру буенча конкурс турындагы Нигезләмә нигезендә билгеләнә.

8. Яшьләр парламенты составына Татарстан Республикасы Дәүләт Советы каршындагы Яшьләр парламенты әгъзалары, Зеленодольск муниципаль районы яшьләре керә ала. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы каршындагы Яшьләр парламенты әгъзаларын, Зеленодольск муниципаль районы яшьләрен тәкъдим итүче әгъзаларны, яшьләр парламенты составына кертү конкурстан тыш гамәлгә ашырыла.

9. Яшьләр парламенты әгъзалары булып, Яшьләр парламенты составына кертелгән көнгә 35 яшькә кадәрге, Зеленодольск муниципаль районы составына керүче Совет, шәһәр һәм авыл җирлекләре советы депутатлары була ала. Яшьләр парламенты составына депутатларны кертү конкурстан тыш гамәлгә ашырыла.

10. Яшьләр парламенты составына керү нияте турында гариза депутат тарафыннан яшьләр парламенты Советына җибәрелә.

11. Яшьләр парламенты Регламентында каралган очракларда, Яшьләр парламенты әгъзасы вәкаләтләре вакытыннан алда туктатыла.

## IV. Яшьләр парламенты эшен оештыру

12. Яшьләр парламентының беренче утырышын алдагы чакырылыш Яшьләр парламенты рәисе ачып җибәрә, ул булмаганда – Зеленодольск муниципаль районы Башлыгы урынбасары.

13. Беренче утырышта Яшьләр парламенты әгъзалары ачык тавыш бирү белән Яшьләр парламенты әгъзалары арасыннан рәисне, рәис урынбасарларын, җаваплы секретарьны сайлыйлар, Яшьләр парламенты Советының сан составын билгелиләр һәм аның әгъзаларын сайлыйлар, Яшьләр парламенты комиссияләрен төзиләр һәм аларның рәисләрен сайлыйлар. Яшьләр парламенты рәисләренә кандидатлар үз эшчәнлекләре программаларын тәкъдим итәргә тиеш. Яшьләр парламенты рәисе урынбасарларының саны Яшьләр парламенты рәисе тәкъдиме белән билгеләнә.

14. Яшьләр парламенты утырышы, әгәр анда Яшьләр парламенты әгъзаларының билгеләнгән санынннан кимендә өчтән икесе катнашса, тулы хокуклы була.

15. Яшьләр парламенты үз эшчәнлеге юнәлешләре буенча эшче һәм эксперт төркемнәре төзергә, тәкъдимнәр эшләргә һәм кабул итәргә, аларны җирле үзидарә органнарына җибәрергә хокуклы.

16. Яшьләр парламентының сайланган әгъзалары санының күпчелеге тавыш бирсә, Яшьләр парламентының карары кабул ителгән дип санала, әгәр аның өчен тавышлар тигез булган очракта, рәис тавышы хәлиткеч булып булып санала.

17. Яшьләр парламенты советын Яшьләр парламенты рәисе җитәкли, аның вәкаләтләре Яшьләр парламенты регламенты белән билгеләнә.

18. Яшьләр парламенты Советы:

1) Яшьләр парламенты һәм аның комиссияләре эшен оештыра һәм координацияли;

2) Яшьләр парламенты регламентын эшли һәм аны яшьләр парламенты раславына тәкъдим итә;

3) чираттагы елга Яшьләр парламентының эш планнарын эшли һәм аларны Яшьләр парламентына раслауга тәкъдим итә;

4) Яшьләр парламенты регламенты нигезендә башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыра.

19. Яшьләр парламентының эшче һәм эксперт төркемнәре Яшьләр парламенты утырышларында карау өчен үз функцияләренә туры китереп рекомендацияләр һәм карарлар проектларын әзерлиләр.